**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » 07 2021 № 227

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 ел, 11 ноябрь, №301а карары белән расланган «2015-2023 елларга Аксубай муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2023 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июнь, №512 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 24 июнь, №485 Карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 ел, 11 ноябрь, №301а карары белән расланган «2015-2023 елларга Аксубай муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына (27.04.2016 № 240, 22.08.2018 № 456, 28.12.2018 № 743, 27.03.2019 № 614, 03.08.2020 № 499 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2015 – 2023 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» муниципаль программасында (алга таба- Программа):

исемендә «2015 – 2023» саннарын «2015 – 2024» саннарына алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлында «2015 – 2023» саннарын «2015-2024» саннарына алыштырырга;

«Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2015-2021» саннарын «2015-2024» саннарына алыштырырга;

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Программаны финанслау күләме еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән</td>
<td>Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 600 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сумнарда)
<table>
<tr><th>ел</th><th>ТР Аксубай муниципаль районының җирле бюджеты акчалары</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>100,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1000,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш</td>
</tr>
</table>

«Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының беренче абзацында «2023 ел ахырына» сүзләрен «2024 ел ахырына» сүзләренә алыштырырга;

Программаның 3 нче бүлегендә сигезенче абзацында «2015 –2023» саннарын «2015 – 2024» саннарына алыштырырга;

«2015-2023 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» һәм программа чаралары буенча финансла» муниципаль программасының 5 һәм 6 бүлекләрен яңа кушымта итеп бирелгән редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев